| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2020 Балык Бистәсе штп. № 112пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында

Россия Федерациясе Президентының “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру хакында” 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру хакында” 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 25.03.2013 ел, № 55пи карары белән расланган үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән мәгълүматларны тапшыру срогын 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов